**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге**
**Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324**
**Азнакаевский район**
**Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46**
Chal.Azn@tatar.ru

**Үзәк урам, 39, Азнакай районы**
**Чалпы авылы, 423324**
**Тел. (8-5592) 35-5-46,**
**факс (8-5592) 35-5-46**
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01» ноябрь 2024 ел № 9

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чалпы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чалпы т. п., Центральная ур., 24 нче йорт адресы буенча урнашкан Чалпы авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елның 15 ноябрендә 15.00 сәгать 00 минутта 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:
- Чалпы торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамына, Яңа урамга, Гагарина урамына, Казан урамына, Ленин урамына, Садовая урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү);

- Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Чалпы авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләре күрсәтү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү ,Чалпы торак пунктында үлән чабу хезмәтләре өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы __________ А.М.Мөхәмәтшин
(имза) (имза расшифровкасы)